**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА НОВОИГАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯНА ИГЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Иглай ав. **КАРАР**

«10» ноябрь 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Иске Иглай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Иглай авыл җирлегенең Иске Иглай торак пунктында гыйбадәтханә янында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 21 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

3.1. «Яңа Иглай авыл җирлеге Иске Иглай торак территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Иске Иглай торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту»;

- Иске Иглай авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3.2. Суүткәргеч төзү, халыкны эчәр су белән тәэмин итү өчен җыелган 2022 елда гражданнарның үзара салым акчаларының калдыгын 80000 (сиксән мең) сум 00 тиен һәм 321411 (өч йөз егерме бер мең дүрт йөз унбер) сум 05 тиен күләмендә

республика акчаларын су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкаруга файдаланырга ризамы.»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Яңа Иглай авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Х. Ханәфиев